СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК


НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

26 август, 1998 ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 97 (8254) | Бәясе билгеләнгәнчә

## РАЙОНДА ПРЕМЬЕР - МИНИСТР БУЛДЫ

***Инде хәбәр иткәнебезчә, узган җомга көнне Нурлатка ТРның Премьер - министры Рөстәм Нургалиевич Миннеханов килде. Визит барышында иптәш Миннехановны кәефле гаҗәпләндергән һәм чынлап торып кызыксындырган нәрсәләр байтак булды.***



Олы кунакның Нурлат яклары белән танышуы "Татнефтепром" ОАОсының Зүзәй нефть һәм газ чыгару промыселыннан башланды. Биредә район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин [illegible] "Татнефтепром" [illegible]Осы Генераль директоры Р.К.Зарипов Премьерны промыселның бүгенге эшчәнлеге һәм киләчәге белән таныштырдылар, бүген 16 скважина бораулаган бу ятмада киләчәктә скважиналар санын 300гә кадәр җиткерү мөмкинлеге һәм нияте барын белдерделәр һәм шуның белән биредә куәтле битум заводы төзүне икътисадый отышлы дип нигезләделәр. Иптәш Миннеханов завод төзелешен кызыксынып карады. Киләчәктә елына 60 мең тонна промышленность һәм юл битумы, 30 мең тонна котельня - мич ягулыгы (мазут) бирәчәк [illegible]әтле корылманы районга гына түгел, республика мәнфәгатьләренә дә хезмәт итәчәк объект дип бәяләп ул аны мөмкин кадәр тизрәк эшкә җибәрү зарурлыгын куәтләде.

"Төрнәс" спирт заводында да иптәш Миннехановны шундый тере кызыксыну ташламады. "Татспиртпром" җитештерү берләшмәсе генераль директоры Р.Р.Шәйхетдиновка байтак кына сорауларга җавап бирергә туры килде. "Төрнәс" спирт заводы" дәүләт унитар предприятиесендә барган реконструкцияне ноябрьдән дә калмыйча төгәлләргә, кичекмәстән югары сыйфатлы спирт җитештерә башларга, шуңа параллель рәвештә берочтан чиста аракы җитештерү линиясе төзүне дә сузмаска, диде Премьер һәм аңа зур киләчәк юрады.



Рәсемнәрдә: Хөкүмәт башлыгын һәркайда кунакчыл каршы алдылар; "Кейс" кабинасындагы уңайлык Премьерны да таң калдырды.

Аннан делегация район хуҗалыкларына юл тотты. Премьер яңа оешкан "Өмет" агрофирмасының "Агрокультура" кооперативы, "Киекле" ассоциациясе үрнәгендә терлекчелектә чыгымга каршы механизмның кертелүе һәм кулланылуы белән танышты, "Альфа - лаваль" швед саву җайланмасының Нурлат машина төзү заводында төзеләчәк аналогына аерата кызыксыну белдерде, хуҗалыкларда сөт пастеризаторлары куюны хуплады.

(Ахыры 2нче биттә).

## УҖЫМ ЧӘЧҮДӘ СОҢГА КАЛМЫЙК

***"Уңыш - 98" матбугат үзәге хәбәр итә***

**Бу көннәрдә игенчеләр алдында торган бурычлар арасында уҗым чәчүне тизрәк төгәлләүдән дә мөһиме юктыр. Кичәге көнгә район буенча бу эш 13 мең гектарга якын мәйданда уздырылды һәм планның яртысыннан артык китте. Дөрес, соңгы бер көндә чәчелгәне мең гектардан аз гына артыграк булды, һәм инде бу эшнең оптималь сроклары узып баруын искә алсак, бик тә ашыга төшәргә кирәклеге аңлашыла. Әлегә арыш һәм көзге бодайны иксен дә планлаштырган кадәр чәчеп куйган хуҗалык бер генә - "Родина" кооперативлар берлеге. "Рассвет", "Сәлчә" һәм "Игенче" - арыш, "Заветы Ильича" һәм "Кондырча" уҗым бодаен ниятләнгән кадәр чәчтеләр. Ә менә "Комбайн", "Тәрнәс", "Чирмешән", Кузнецов исемендәге, РСУ һәм нефтебаза ярдәмче хуҗалыкларында план яртылаш та үтәлмәгән әле.**

**Бер үк вакытта быелгы уңышны җыеп алуны да ашыктырасы бар. Кичәге көнгә борчакны 300 гектарга якын гына мәйданда суктырасы калса да, сабан бодаеның чирегеннән артыгы гына җыелган әле. Соңгы көннәрдә бу эшне "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыгында, "Заветы Ильича", "Таң", "Үрнәк", Хафизов исемендәге һәм кайбер башка хуҗалыкларда шактый тизләттеләр, ә менә нефтебаза ярдәмче хуҗалыгында, "Игенче", Родина" һәм кайбер башка хуҗалыкларда ул эшнең темпы канәгатьләнерлек түгел әле. Бодайның тулай җыеме әлеккечә үк Мичурин исемендәге хуҗалыкта иң күбе, "Киекле", "Заветы Ильича", "Кондырча", "Таң" һәм Хафизов исемендәге хуҗалыкларда да чагыштырмача ишле.**

**Товар кредиты исәбенә ашлык тапшыруга килгәндә, "Сәлчә"нең кичәге көнгә 450 тонна бодай тапшыруын әйтмичә булмый һәм бу район буенча тапшырылган барлык бодайның уннан беренннән күбрәк. Шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгының тапшырган бодае да заданиедәгедән артып китте инде, "Алга"ныкы 560 тонна булды, Муса Җәлил исемендәге, "Рассвет" хуҗалыкларының арпа буенча бурычлары күп калмады. Тик соңгысының тапшырган бодае юк дәрәҗәсендә аз әле, бодай буенча иң зур бурычлы Синдряков исемендәге, Кузнецов исемендәге хуҗалыклар да бу эштә бик ашыкмыйлар.**

**Терлек азыгы туплауда хәзер төп басым кукуруз силослауга ясала. Соңгы көннәрдә бу эшне "Алга", Кузнецов исемендәге, Синдряков исемендәге, "Тәрнәс", Хафизов исемендәге, нефтебаза ярдәмче хуҗалыкларында тизләттеләр, ә менә Муса Җәлил исемендәге, "Дуслык", "Комбайн", "Родина", "Сәлчә", "Чирмешән" һәм РСУ ярдәмче хуҗалыкларында бер генә тонна да силос юк әле.**

## МӘГАРИФ МИНИСТРЫ КИЛДЕ

***Узган шимбә - 22нче август көнне районга ТРның Мәгариф министры Фарис Фахразиевич Харисов килде.***

***Ул район һәм шәһәр хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин белән очрашып сөйләште, укытучыларның традицион август киңәшмәсендә катнашып чыгыш ясады. Фарис Фахразиевич аннан соң капиталь ремонт бара торган Киекле, Кизләү мәктәпләрендә булды, Фома урта мәктәбе һәм балалар бакчасы белән танышты. Аннан ул иң ерак мәктәпләрнең берсе - Торнояс мәктәбенә барды, "Әкият" укыту - тәрбия комплексында булды.***

***Министр яңа төзелешләр белән дә кызыксынды, 99нчы ПТУ һәм 1296 урынлы яңа мәктәп төзелеше белән танышты.***

(Укытучылар конференциясе турындагы җентекле язманы газетаның киләсе саннарыннан укырсыз).

## МӘКТӘП ЯРМИНКӘСЕ ГӨРЛӘП ҮТТЕ

***Укытучыларның август киңәшмәсе иртәсендә үзәк мәйданда укучылар ярминкәсе үткәрү матур традициягә әйләнде инде.***

Ярминкәнең арзан, мул дигән даны быел да нурлатлыларны иртәнге сәгатьтән үк мәйданга җыйды. Чыннан да, ниләр генә юк иде бу көнне прилавкаларда: мәктәп яны участокларыннан җыелган яшелчәләр, җиләк - җимешләр, кайнатмалар, тозланган, консервланган яшелчәләр. Моннан тыш, балалар хезмәт дәресләрендә, түгәрәк занятиеләрендә әзерләгән кул эшләре, теккән киемнәр, йорт кирәк - яраклары, хәтта йорт җиһазларына кадәр табарга була иде ярминкәдән. Мәйданда сату белән 41 урта, 9 башлангыч мәктәп, 12 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе коллективы катнашты, анда 36 мең сумлык 16 тонна яшелчә һәм яшелчә культуралары сатылды. Моннан тыш, теккән киемнәр, урын - җир әйберләре, кухня кирәк - яракларын һ.б. да бик теләп алдылар. Яшь сәүдә хезмәткәрләре үз сату нокталарын бизәү, сәүдә итү осталыкларын да елдан - ел арттыра баралар, анысыннан да һәркем канәгать калды.

Махсус комиссия, ярминкәне карап, быел да иң мул продукция алып чыгучыларны аерым билгеләде.

Урта мәктәпләр арасында I урынны 3425 сумлык продукция саткан Түбән Нурлат мәктәбе алды. Икенче урында шәһәрнең өченче (2982 сум), өченчедә - дүртенче (2906 сум) мәктәбе булдылар. Башлангыч мәктәпләр арасында урыннар түбәндәгечә билгеләнде:

I урында - Абрыскино, IIдә Кече Камышлы, IIIдә - Ерепкино мәктәпләре.

Мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләре арасында "Ивушка" беренче булды. Урта Камышлы, Тимерлек учреждениеләре II - III урыннарга чыктылар.

**С.НУРУЛЛИНА.**

***Авыллардан язалар***

## ГАЗЛЫ БУЛДЫК

Авылга табигый газ килүне Кычытканлы халкы берничә ел түземсезләнеп көтте. Ниһаять, ул шатлыклы көн килде, авыл зәңгәр ягулыкка тоташтырылды. Бу көннәрдә газ плитәләрен тоташтыру төгәлләнеп килә. Шуның белән беррәттән, газ мичләре әзер булган хуҗалыкларга да табигый газ киләчәк. Шулай итеп, авылыбыз баллонлы газ кайтару мәшәкатеннән арынып килә. Рәхәтен күреп, исән - сау яшәргә язсын!

**З.ИСМӘГЫЙЛЕВА.**
**"Татарстан" КХАсы.**

## ЫНДЫР ТАБАГЫНДА ЭШ КЫЗУ

"Комбайн" КХАсының ындыр табагы бу көннәрдә киеренке эшкә чумды. Ашлыкны кырдан җыеп кайтару беренче җаваплы эш булса, аны чистарту, киптерү һәм саклау аннан да әһәмиятлерәк бурычка әйләнә бит һәм биредә моны тирәнтен аңлап, оешканлык белән эшлиләр. Ашлыкны чистартып, амбарда сакларлык хәлгә җиткереп орлыкка салалар, фураж әзерлиләр. Кырдан кайткан игенне Фоат Фәйзиханов үлчәп тора. Алиф Мәхмүтов, Җәүдәт Зәйниев ашлыкны эшкәртәләр, ындыр табагы эчендә ашлыкны тиешле урынга машинасы белән Фоат Нәбиуллин ташып тора. Эшкәртүдә хатын - кызлар да катнаша, әлбәттә. Альбина Сәмәрханова, Гөлфирә Зәйниева, Гүзәл Гарифуллина быел анда иң активлар. Шулай ук Сәлим Нәбиуллин һәм Нәкыйф Мәхмүтов та үзләренә тапшырылган эшне зур җаваплылык белән алып баралар.

**С.ФӘТХЕТДИНОВА.**
**Яңа Әмзә авылы.**

# РАЙОНДА ПРЕМЬЕР - МИНИСТР БУЛДЫ

*(Ахыры. Башы 1нче биттә).*



*Рәсемнәрдә: Премьер - министрны кызыксындырырдай эшләр һәр хуҗалыкта бар иде.*



Дуңгызчылыкны үстерүдә махсуслашучы "Нурлат" агрофирмасында хөкүмәт җитәкчесе җитештерүдән башлап эшкәртү, сатуга кадәр циклны эченә алган хуҗалык итү механизмы белән танышты. Хуҗалар киләчәктә конкуренциягә сәләтле 50дән артык төрдә продукция чыгаруга исәп тоткан немец җиһазларыннан торган цех ачу ниятләре белән дә бүлештеләр. Бирелә Премьер - министрны "Татмясопром" холдинг компаниясе президенты Ә.Г.Булатов та каршы алды.

Премьер - министрны һәр булган урында яңалык, кызыклы башлангыч көтә иде. Югары Нурлат нәселле атлар фермасында булганнан соң, ул басуда "Кейс" комбайнының эше белән танышты. Рөстәм Нургалиевич үзе дә бу комбайн руле артына утырып, ашлык суктырып карады. Аның идарә итүдә гадилеген бәяләде, шуңа өстәп, экономик нәтиҗәлелек күрсәткечләрен дә ишеткәч, үзебезнең КамАЗда шундый комбайннар җитештерергә алынырга дигән фикерен белдерде.

Нурлат шикәр заводының җылылык - энергетика үзәгендә һәм диффузия төзелешендә барган реконструкцияне карады ул, заводның җитештерү куәтен арттыруда иң төп рольне уйнаучы үзара бәйләнгән бу ике узелда реконструкцияне дәвам итүгә финанс табуның бер мөмкинлеге итеп акцияләр белән эшләүне күрсәтте.Ул предприятиенең җитештерү фондлары һәм куәте артуга бәйле рәвештә өстәмә акцияләр чыгару һәм аларны файдалы урнаштыруны күздә тота иде.

Премьер шулай ук "Нурлат- Октябрь" элеваторының яңа тегермәнендә булды, үз оннарыннан пешерелгән икмәктән авыз итте. Соңгы нокта итеп Нурлат аэропортын карап чыкты.

"Күп эшләр башкарылган, зур башлангычлар бар",- диде Р.Н. Миннеханов, Нурлатта алган тәэсирләре белән уртаклашып һәм кайбер башлангычларны дәвам итү юнәлешендә уртак ниятә килүләрен белдерде, беренче чиратта Зүзәй битум заводын төзеп бетерү һәм шикәр заводында реконструкцияне тәгәлләүгә финанс ярдәме күрсәтергә вәгъдә бирде.

Делегация составында Дәүләт коммуналь милек идарәсе рәисе Д.М. Бикбов һәм башка рәсми дәүләт эшлеклеләре бар иде.



***С.ХӘЙРУЛЛИНА.***

***Н.АЗИЗОВ фотолары.***

### БЕЗНЕҢ ИНТЕРВЬЮ

# «АК БАРС» ГАРАНТИЯЛИ

***"Ак Барс" банкының Чистай филиалы Нурлат өстәмә офисы - районда яшәп килгән 5 банк арасында иң яше.Күпләр әле ул банк турында хәбәрдар да түгелләрдер.Шуңа да бүген без "Ак Барс" банкының Нурлат өстәмә офисы начальнигы Р.Г.Билалов белән банк һәм ул күрсәтә торган хезмәтләр турында район халкына киңрәк мәгълүмат бирү максатыннан әңгәмә корабыз.***

## КЫСКАЧА БЕЛЕШМӘ

**"Ак Барс" акционерлык коммерция банкы Россия Федерациясе Үзәк Банкында 1993 елның 29 ноябрендә теркәлгән. Банкның Татарстан һәм Россия Федерациясе территориясендә 11 филиалы һәм 36 вәкиллеге бар, аның филиаллары даими рәвештә үсә бара. "Ак Барс" банкы 1994 елның 7нче июленнән ТР хөкүмәтенең инвестиция программаларын үстерүгә вәкаләтле. 1996 елның 15 июленнән ТР хөкүмәте вексельләре әйләнешенә вәкаләт ала. Аның корреспондентлык челтәрендә 40тан артык банк - партнерлар исәпләнә.**

**Банкның рейтингы елдан - ел үсә бара. 1997 елда Русия рейтингы мәгълүматлары буенча, ул динамик үсештә булган банклар рәтенә керсә, капитализация һәм табыш ягыннан банк беренче 50 банк арасында 1нче һәм 5нче урыннарда. Былтыр Русиянең иң ышанычлы 10 банкы исемлегенә керсә, быел инде ул ышанычлы 5 банк исемлегендә исәпләнә.**

- Безнең районда 1994 елның июнендә "Ак Барс" банкының вәкиллеге эшли башлады. Аның төп функциясе - юридик һәм физик затлар арасында чек - вексель әйләнешен тәэмин итүдән гыйбарәт иде. Быелның март аеннан "Ак Барс" идарәсе карары буенча вәкиллекнең юридик һәм физик затларга банк хезмәте күрсәтүен киңәйтү максатында ул Чистай филиалының өстәмә офисы итеп үзгәртелде.

*- Шулай итеп, сез хәзер нинди хезмәтләр күрсәтәсез була инде?*

- Хәзер без халык һәм оешма - предприятиеләр белән кертем операцияләре үткәрәбез, юридик һәм физик затларга расчет - касса хезмәте күрсәтәбез.

13 төрдә кертемнәр кабул ителә, аларның процент ставкалары елына 40 процентка кадәр җитә. Моннан тыш, 15нче июльдән без валюта белән эшли башладык: валюта алыштыру пункты ачылды, хәзер АКШ долларлары һәм немец маркаларын сатарга яки алырга, чит ил валютасында кертемнәр белән эшләргә мөмкин. Безнең хезмәткә азык -төлек чеклары һәм жетоннарының әйләнешен тәэмин итү, хәтта коммуналь түләүләрне кабул итү дә керә. Без һәр айда 750 мең азык -төлек чегы, 110 мең жетон таратабыз.

*- Һәм сезнең хезмәтләрдән файдаланучылар бармы?*

- Бүгенге көнгә безгә халык 2,0 млн. сум акчасын сакларга салды һәм бу сан кимеми, арта гына бара.

*- Ни сәбәптән халык сезне сайлый дип уйлыйсыз? Район территориясендә моңарчы яшәп килгән "СБС - Агро", "Девон - Кредит" банклары да бар бит әле.*

- Мин аларны ышанычсызлар, дип атарга җыенмыйм, аларның да үз клиентлары аз түгелдер. Безнең "Ак Барс"ны сайлаучылар исә берничә факторны күздә тоталар дип уйлыйм. Бердән, аның рейтингы динамик үсештә булу үзе зур роль уйный. Икенчедән, "Ак Барс" - вәкаләтле хөкүмәт банкы. Ул иң беренче чиратта хөкүмәт программаларының үсешенә хезмәт итә. Димәк, вкладчы үз кертеменең ниндидер башка регион (әйтик, Русия) мәнфәгатьләренә түгел, нәкъ менә үз республикабыз программаларын кредитлауга китәсен аңлый. Үз республикабыз мәнфәгате - димәк, сезнең - безнең тормыш хәлен яхшырту дигән сүз. Мәсьәләнең бу мораль ягы шулай ук еш кына сайлауны хәл итә. Аннан,банкның ТР хөкүмәте исеме белән бәйләнгән булуы да ышанычлылык гаранты бит: республика хөкүмәте әлегә халыкның ышанычын акламый калганы юк. Шуларга өстәп, без банк ышанычлылыгына тагын бер дәлил китерер идек: банкның хөкүмәт каршында валюта операцияләре һәм кыйммәтле кәгазьләр буенча йөкләмәсе чагыштырмача кечкенә, шунлыктан доллар курсы үзгәрү, кыйммәтле кәгазьләрнең бәясе төшү безнең торышка зур куркыныч янамый. Әле менә тагын доллар курсы үзгәрә башлагач, халык арасында башланган ыгы - зыгы нәтиҗәсендә кертемнәрен алырга теләк белдерүчеләргә дә шул хакта аңлатма бирдек. Безнең клиентларга тагын бер яктан борчылырга урын юк: бездә кертемнәрен алырга ниятләүчеләр теләге шунда ук үтәлә, тере акча һәрвакыт бар. Инде бөтен әйткәннәргә тагын бер хәбәр өстисебез килә: шушы көннәрдә финанс кризисыннан чыгу өчен республиканың өч банкы - "Ак Барс", "Волжско - Камский", "Татфондбанк" көчләрен берләштерергә булдылар. Алар бер - берләренә үзара кредитлар бирергә, бергәләшеп икътисадый куркынычсызлыкларын якларга, шулай вкладчылар каршындагы йөкләмәләрен үтәргә килештеләр. Бу хәл иң әүвәл ышанычлылыкны саклау йөзеннән бит. Шунда ук "Ак Барс" банкының игелеклелек акцияләрендә катнашуын да өстисем килә. Ике ел инде ул уку елы башланыр алдыннан 1нче класс укучыларына үзеннән бүләк ясый. Быел шундый бүләк - "Дуслар" китабын районда 700ләп бала алачак.

*- Рәшит Габдрахманович, өстәмә офисның перспективасы бармы?*

- Менә нәкъ шул хакта әйтергә ниятләп тора идем. Хәзер хакимият башлыгы Ф.С.Сибагатуллин инициативасы буенча өстәмә офисны филиал итеп үзгәртү юнәлешендә эш бара. Югарыдан рөхсәт озакка сузылмаска ошый, ул чакта безнең алда мөмкинлекләр һәм бездән районга реаль файда күпкә киңәячәк. Инде тулаем банк киләчәгенә килгәндә, аны ябык типтагы акционерлык җәмгыятеннән ачык типтагы итеп үзгәртү турында карар кабул ителде. Аннан соң аның үз акцияләрен чыгару, аны Русия һәм халыкара фонд базарында урнаштыру нияте гамәлгә керә. Бу да банк өчен өстәмә перспектива ача.

***- Сез элеккеге сәнәгать-төзелеш банкы бинасына урнашкансыз. Халык арасында бу җәһәттән аңлашылмаучылыклар күзәтелмиме?***

- Әйе, үз бинабыз булмау сәбәпле, баш офис безгә элеккеге сәнәгать - төзелеш банкы бинаосын сатып алып бирде. Әмма аңлагансыздыр, безнең арада бернинди бәйләнеш юк, шуңа алдагы хуҗаларга кагылышлы сорауларны без ачыклый алмыйбыз. Хәзер биредә ремонт бара, әмма халыкка банк хезмәте күрсәтүне өзгәнебез юк. Безнең хезмәттән файдаланырга теләүчеләр рәхим итсеннәр! Миңа калса, бүген акчаны банкларда саклау ышанычлырак, отышлырак булуын сөйләп тору урынсыз.

**Әңгәмәдәш - С.ХӘЙРУЛЛИНА.**

# СӘЛАМӘТЛЕК

## ДОНОРЛАР КИРӘК

**_Медицина фәне ничек кенә алга китмәсен, практикада авыруның гомерен әле һаман да донор каны саклап калган очраклар еш очрый. Соңгы вакытта автомобиль транспорты тормышыбызга тирән үтеп кергән һәм производство механикалаштырылган чорда һәлакәтләр торган саен арта һәм аларда зыян күрүчеләрнең күбесенә кеше каны таләп ителә. Тудыру бүлегендә дә канга ихтыяҗ зур, чөнки бала тууы кайчак ана тормышын куркыныч астына куя._**

Донор канының әһәмиятлелеге хакында башка күп мисаллар да китерергә мөмкин булыр иде. Тик, кызганычка каршы, безнең хастаханәдә донор каны мәсьәләсе гаять кискен бүген, гади итеп әйткәндә, ул юк дәрәҗәсендә, чөнки соңгы вакытта кан бирүчеләр көннән - көн азая. 10- 15 ел элек безнең районда меңләгән кеше кан тапшыра иде, ә хәзер атнасына 4 - 5 кеше генә бу адымга батырчылык итә. Ә бит элек кан бирү бушлай иде. Россия Федерациясенең "Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында"гы 1993 елгы Законында донорлар өчен төрле льготалар каралган. Мәсәлән: кан бирә торган һәм медицина тикшерүе үтә торган көннәрдә предприятие нинди милек формасы буенча эшләвенә карамастан, донорны уртача эш хакын саклап эшеннән азат итә. Донор хәрби хезмәткәрләр нарядлардан һәм вахталардан азат ителәләр.

Канны чираттагы отпуск яки бәйрәм вакытында тапшырганда да эш көнендә ял бирелә. Эш көнендә тапшырган очракта икенче яки ул теләгән көнне ял алырга рөхсәт ителә. Бу льготалар бары тик бер тапкыр кан тапшыручылар өчен булса, ике тапкыр тапшырганнарга өстәмә льготалар каралган:

- студентларга стипендия күләме 6 ай дәвамында 25 процентка арттырып түләнә;
- бер ел дәвамында барлык авыру төрләре буенча да хезмәткә сәләтсезлеккә пособие хезмәт стажына бәйсез рәвештә тулы хезмәт хакы күләмендә түләнә;
- ел дәвамында дәүләт яки муниципаль сәламәтлек саклау учреждениеләрендә дәвалау әлеге учреждениеләр бюджеты исәбенә алып барыла;
- ел дәвамында эш яки уку урыныннан санаторий - курорт путевкалары беренче чиратта бирелә.

"Россиянең Мактаулы доноры" билгесе белән бүләкләнүчеләргә югарыда саналганнарга өстәп аерым льготалар каралган:

- дәүләт яки муниципаль сәламәтлек саклау учреждениеләрендә дәвалану чиратсыз;
- теш протезлары бушлай ясала һәм ремонтлана;
- дарулар 50 процент ташлама белән сатыла;
- еллык чираттагы түләүле отпуск аларга җайлы вакытта бирелә;
- таксидан башка барлык транспортларда да бушлай йөрү рөхсәт ителә;
- коммуналь хезмәтләр өчен түләү 50 процентка кадәр киметелә;
- индивидуаль торак төзелеше өчен льготалы ссуда алырга мөмкинлек бирелә.

Хөрмәтле район халкы, сезне район хастаханәсенә кан тапшырырга чакырабыз, чөнки кеше физиологиясе өчен кан бирүнең бернинди зыяны юк бит, ә бәхетсезлек очрагы теләсә кем белән булырга мөмкин. Район үзәк хастаханәсенең кан салу бүлегендә көтәбез сезне. Тапшырылган кан өчен акчалата компенсация ясау мөмкинлеге бар - бүгенге көндә Татарстанда ул 115 сум (Россиядә күпкә кимрәк) тәшкил итә.

**И.МАТЫГУЛЛИН,**
**кан салу бүлеге мөдире вазифасын башкаручы.**

## Күп яшәргә теләсәң...

**_Швециянең абруйлы газеталарыннан берсе, гигиенаның иң гади кагыйдәләрен үтәгәндә, 100гә кадәр яшәргә мөмкин дип исәпли. Иң мөһиме - кулларны юарга онытмаска кирәк..._**

**_БОРЧЫЛУЛАР АЗРАК БУЛСЫН._** Бирелә сезгә гади генә өч кагыйдә ярдәмгә килер. Беренчесе: дөрес сулагыз, борчылган вакытта тын кысыла. Бу исә, үз чиратында, киеренкелекне арттыра. Икенчесе: ешрак тураегыз. Борчылу гәүдә торышына тәэсир итә һәм киеренкелекне арттыра. Өченчесе: эш - гамәлләрегезне контрольдә тотыгыз. Инде барысы да өметсез, начар икән, аны бары тик үзегез генә хәл итә, яхшы якка үзгәртә аласыз.

**_ЕШРАК АРАЛАШЫГЫЗ._** Тикшерүләр күрсәткәнчә, дуслары белән ешрак аралашканда, кешеләр азрак авырый. Сөйләшергә, аралашырга яратучылар, йомыкыйларга караганда, авыруларга икеләтә кимрәк бирешә.

**_КУЛЛАРЫГЫЗНЫ ЮЫГЫЗ._** Безгә салкын тиеп авыручы кешеләр белән бик еш аралашырга, ишек тоткаларын һәм телефон трубкаларын тотарга туры килә. Шуңа күрә кулларны ешрак юыгыз. Моны аеруча ашау - эчү әзерләгәндә һәм ашау алдыннан эшләргә кирәк. Кухняны ешрак җыештырыгыз.

Ашаганнан соң ук утырмагыз һәм ял итәргә ятмагыз. 15 минут кухняны җыештырып алыгыз. Бу сезгә якынча 40 калорийны киметергә ярдәм итәр.

**_ЕШРАК КӨЛЕГЕЗ._** Тикшерүләр күрсәткәнчә, көлү иммунитет системасын көчәйтә, калорияне күбрәк яндыра һәм кәефне күтәрә.

**_ЧӘЧӘКЛӘР ҮСТЕРЕГЕЗ._** Сез фатирыгызда һаваны сафландырырсыз, бүлмәдә кислород күбрәк булыр.

**_АРТ БЕЛӘН АЛГА ТАБА ЙӨРЕГЕЗ._** Ашаганнан соң саф һава сулап керү файдалы. Паркта арт белән алга таба йөрүдән тартынмагыз. Шулай йөргәндә, сез калорияне икеләтә күбрәк яндырырсыз.

**_ЙОКЫ АЛДЫННАН._** Йокыга ятар алдыннан 50 - 100 тапкыр чүмәшеп алсаң (монысы сезнең ничек күнегүегезгә бәйле) һәм 20 - 40 тапкыр кулларны хәрәкәтләндерсәң бик файдалы.

**_ЯТКАН УРЫННАН КИНӘТ СИКЕРЕП ТОРМАГЫЗ._** Төнлә умыртка сөякләре арасына сыекча җыела. Шуңа күрә, уянгач берничә тапкыр киерелергә, умыртка баганасына уяну өчен вакыт бирергә кирәк. Лифтлардан һәм эскалаторлардан файдаланырга тырышмагыз. Табиблар раславынча, баскычлар буйлап көнгә алты минут йөрү гомерне ике елга озайта икән.

**_КУЕ СӨТ ЭЧМӘГЕЗ._** Салатларны күбрәк ашагыз. Майлылыгы аз булган сөтне ешрак эчегез, ашамлыкны зәйтүн маенда әзерләгез. Ашау алдыннан бер стакан су эчү аппетитны киметә.

**_ТЕЛЕВИЗОР АЛДЫНДА КҮП УТЫРМАГЫЗ._** Телевизор караганда хәрәкәтләнергә тырышыгыз. Сүз әйтергә теләсәң, икенче бүлмәдәге кешегә кычкырмагыз, сүзегезне аның янына килеп әйтегез.

**_ҺӘР КӨННЕ САРЫМСАК АШАГЫЗ._** Көн саен бер бүлемтек сарымсак ашасаң, йөрәк авырулары 18 процентка кимәтә.

**_Е ВИТАМИНЫН КҮБРӘК КУЛЛАНЫГЫЗ._** Британия галимнәре фикеренчә, кем дә кем Е витамины күп булган ризыкны куллана икән, андыйларның йөрәк авыруы бик сирәк була.

Барлык киңәшләрне дә берьюлы үтәргә тырышмагыз. Берсен сайлап алыгыз һәм аны бер ай дәвамында башкарыгыз. Аннары икенчесенә, өченчесенә керешегез. Шулай эзлекле рәвештә дәвам итегез. Бер елдан соң сез үзегезне яңадан тугандай хис итәрсез.

**("Заман - Татарстан" газетасыннан).**

## ТЕШЛӘРЕГЕЗ КӨЛЕП ТОРСЫН



Таза булсын, черемәсен өчен без тешләребезне көн саен чистартып торабыз. Ләкин теш щеткасының нинди булуына игътибар итмибез диярлек.

Хәлбуки, авыз һәм тешләрнең сәламәтлеге өчен теш щеткасының сабы, башы, кылларының катылыгы, нинди материалдан ясалуы мөһим факторлардан исәпләнә. Белгечләр, щетканы сатып алганда, түбәндәгеләргә дикъкать итәргә киңәш бирә:

Щетканың башы кечерәк һәм овалсыман булуы яхшы. Кыллары щетка башына бик нык беркетелгән булсын.

Теш чистартканда, щеткага артык басмагыз, чөнки аның урт итенә зыян китерүе мөмкин. Шуны истә тотыгыз, сыгылмалы, бераз гына дугаланып торган "муенлы" щетка алырга тырышыгыз.

Табигый материалдан эшләнгән теш чистарткычны алмагыз, синтетик материалдан ясалганы яхшы.

Теш чистарткычлар каты, уртача каты һәм йомшак кыллы була. Кагыйдә буларак, авыз куышлыгы һәм тешләр өчен иң кулае - йомшак кыллар. Каты кыл озакка чыдый, ләкин аның теш эмаленә һәм урт итенә зарар китерүе мөмкин. Әгәр тешне еш чистартсагыз, йомшак кыллысын алыгыз.

Щетка сабы тоту өчен уңайлы булсын. Аның озынлыгына һәм калынлыгына игътибар итегез. Йомры сап әйбәт түгел. Иң яхшысы - озынча дүртпочмак рәвешендәге сап отышлы.

**("Заман - Татарстан" газетасыннан).**

## БЕР КУРКЫНЫЧ АВЫРУ ТУРЫНДА

Соңгы 3- 4 елда районда хайваннар тешләүдән зыян күргән кешеләр саны кискен артты: Медицина ярдәме күрсәтүне сорап 1995 елда 199 кеше, 1996 елда - 206, 1997 елда - 231 кеше мөрәҗәгать иттеләр, ә агымдагы елның 5 аенда тешләнгән яралар белән 107 кеше теркәлде. Май аенда мөрәҗәгать итүчеләр саны аеруча күп - 32 кеше. Этләр, мәчеләр, күселәр, атлар һәм билгесез кимерүчеләр тешләгән очраклар бар.

Котыру - көчле вируслы авыру, ул нерв системасын зарарлый һәм котылгысыз рәвештә үлемгә китерә. Вирус авыру хайваннарның селәгәй бизләрендә һәм ми тукымасында була. Кеше организмына вирус тешләгәндә, тырналганда, тиредәге яра һәм лайлалы өслекләр аша, яки авыру хайванның селәгәе зарарланмаган лайлалы тышчаларга эләккән вакытта күчә. Котырган кешенең авыруы башка кешеләргә йокмый, шул рәвешле инфекция чыганагы булып бары тик хайваннар санала. Тешләүләр баш һәм арка миенә якын булган урыннарда, ягъни башта, биттә, кул бармакларында булганда аеруча куркыныч.

Котыруның яшерен чоры кешеләрдә берничә көннән алып бер елга һәм аннан да озакка сузылырга мөмкин. Әмма 30 - 90 көннәр чамасы ешрак очрый.

Әгәр кешене нинди дә булса хайван тешләгән икән, аның селәгәе тигән яра яки тире һәм лайлалы өслекләрне сабынлы су агымы астында җентекләп юарга, яраның читләрен йод эремәсе белән эшкәртергә кирәк. Авыруның билгеләре нык беленгәннән соң котырудан дәвалауның уңышлы чаралары юк. Котырган кешегә үзвакытында вакцинация үткәрелмәгән булса, аның үлеме котылгысыз. Авыруны бары тик прививкалар гына коткара ала һәм аларның нәтиҗәлелеге медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итү вакытына бәйле.

Авыруның яшерен чоры этләрдә 2- 8 көн дәвам итә һәм котыру вирусы белән зарарланган хайван авыруның беренче билгеләре күренгәнчегә кадәр үк 10 көн алдан инде куркыныч була. Авыруның беренче көннәрендә эт хуҗасының эндәшүенә теләр - теләмәс кенә җавап бирә, нинди дә булса караңгы, аулак урынга кертергә тырыша, аннан соң ярсыну башлана. Эт бер сәбәпсез өрә, һава йотынгандай итә, төрле әйберләр каба, үзенең тирәсендәге бөтен нәрсәгә - хайваннарга, кешегә, хәтта коймага ыргыла. Ярсулы хәлендә ул 50 км. араны да чабып үтәргә мөмкин.

Йорт хайваннары асраучылар эт һәм мәче тоту кагыйдәләрен үтәргә, ә җәмәгатьчелек аларның бу кагыйдәләрне үтәүләрен таләп итәргә бурычлы. Менә алар:

эт һәм мәчеләрне бер гаилә яшәгән аерым фатирларда асрау санитар- гигиена һәм ветеринар - санитар кагыйдәләрне үтәгән очракта гына рөхсәт ителә. Эт һәм мәчеләрне баскыч мәйданчыкларында, чардакларда, коридорларда һәм шундый башка урыннарда, коммуналь фатирларда, шулай ук балкон һәм лоджияләрдә асрау рөхсәт ителми.

**(Ахыры 4 нче биттә).**

# «ИГЪТИБАР: БАЛАЛАР!» АЙЛЫГЫ



***"Игътибар: балалар!" айлыгы республикада ел саен ике мәртәбә - язын һәм көзен уздырыла. Бу юлы ул августның 15еннән сентябрьнең 15енә кадәр барачак.***

Районда балаларның юлда имгәнүләре мәсьәләсендә хәл ничек тора соң?

1998 елда районда балалар катнашында өч юл - транспорт вакыйгасы булды. 23 гыйнварда Нурлат - Базарлы Матак юлында бозлавыкта "Жигули" шоферы Р.Сафин идарә итә алмыйча җәяүлеләрне бәрдерде һәм 6 яшьлек малай һәлак булды. 13 майда мотоциклчы Г.Фәтхетдинов тизлекне арттыра һәм Вахитов урамында мәктәп яшенә җитмәгән бер кызчыкны таптата. 6 июльдә ВАЗ - 2106 шоферы А.Светкин гаебе белән ике җәяүле хастаханәгә китерелде, шуларның берсе - 13 яшьлек малайның бот сөяге сына...

ГИБДД хезмәткәрләре балалар катнашында була торган юл - транспорт фаҗигаләренең сәбәпләре элеккечә үк:

транспорт чарасы артыннан көтмәгәндә килеп чыгу, машина йөри торган урыннарда уйнау, якынлашып килүче транспорт алдыннан гына юл аркылы чыгу, юлдагы хәлнең ниндилеген күрү мөмкинлеге җитмәүдә дип исәплиләр. Башка сәбәпләрен дә китерергә мөмкин. Алары: юлларның начарлыгы, юл билгеләренең җитәрлек булмавы, балалар психологиясе, иң гади генә игътибарсызлык, тротуарлар булмау һ.б. Сезонлы сәбәпләрне дә истән чыгармаска кирәк: кыш көне бозлавыкта машинаны туктатканчы күп ара үтелүе, балаларның юлга чыгып тимераякта яки чанада шуулары...

Ә җәй көне? Бу айларда республика юлларында 376 авария булып, аларда 4 бала үлде һәм 35е имгәнде. Анализ аварияләрнең җомга һәм чәршәмбе көннәрендә, көндезге сәгать 1дән 2гә, кичке 5тән 6га кадәр ешрак булуын күрсәтә.

Безнең районда уздырылган рейдлар балаларның велосипедта йөрергә ратуларын күрсәтә. Кайчагында балалар мәктәптә укытыла торган яшәеш иминлеге нигезләре турында бөтенләй исләреннән чыгаралар кебек тоела: машина иң күп йөри торган урыннарга велосипедта, кайчагында икешәр - өчәр кеше утырып та чыгалар алар. Кичке якта велосипедта йөрүче балаларны да күрергә туры килә. Ә бит велосипед - иң сакланусыз транспорт төре, машинага әз генә бәрелү дә фаҗигага китерергә мөмкин.

Юл - транспорт вакыйгаларын кисәтү максатыннан ел саен районда хәрәкәт иминлеге фонды һәм район мәгариф бүлеге бергәләп күп кенә чаралар уздыралар. Автоинспекция хезмәткәрләре мәктәпләрдә булып балалар алдында чыгышлар ясыйлар. Күп кенә мәктәпләрдә махсус почмаклар, кайсыларында класс бүлмәләре җиһазланган. 4 нче мәктәп базасында мини автомәйданчык җиһазлана башлады. Картинг клубының эшен яңарту планлаштырыла.

Ата - аналарга һәм укытучыларга мөрәҗәгать итеп шуны әйтәсе килә: юк кына сәбәптән дә балаларның гомере юлда өзелү бигрәк тә аяныч бит. Шуңа күрә, әйдәгез әле, балаларыбызның юл хәрәкәте кагыйдәләрен белүе һәм үтәве турында барыбыз бергәләп кайгыртыйк, балаларыбызның иминлеге турында кайгыртуны уртак эш итик әле.

**Г.ГЫЙМАЛЕТДИНОВА.**

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Киекле авылында яшәүче кадерле **әниебез, кодагыебыз Фәридә Галәветдинованы** чын күңелебездән туган көне белән котлыйбыз. Зур, тату гаиләсенең уңган хуҗабикәсе, сөекле әниебез, хөрмәтле кодагыебызның киләчәк тормышына да якты көннәр, тигезлек, бәрәкәтле муллык, исәнлек телибез. Ходай безгә гомер буе бергә яшәргә, синең һәр бәхетле көнеңә бергәләп сөенергә язсын.



**Иң изге теләкләр белән**
**улы Илнар, килене Люция,**
**оныгы Ләйлә, кода -кодагыйлары.**

26 августта хезмәттәшебез **Миннегөл Мингәрәй кызы Әбҗаббарованың** туган көне.

Бөтерчектәй җитез бухгалтерыбызның яраткан эше, тугры дуслары, тату гаиләсе, балалары, туганнары бар - шул бәхеттән ходай аны беркайчан аермасын!



Сәламәт яшә, килер көнең имин, якты булсын, һәркем өчен кирәклегеңне, гаиләң өчен кадерле булуыңны тоеп гомер ит.

**"Дуслык" район газетасы коллективы.**

# БЕР КУРКЫНЫЧ АВЫРУ ТУРЫНДА

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә).*

Шәһәрдә аерым гражд102ннар, учреждение, оешмалар карамагындагы этләр мәҗбүри тәртиптә өч айлыктан башлап һәм токымына бәйсез рәвештә ветстанциядә теркәлергә һәм яңадан теркәлергә тиешләр. Яңа алынган этләр эт хуҗаларының тиешле түләүне кертүләре турындагы документ күрсәтелгәннән соң бер атна эчендә теркәлергә тиешләр. Кулланудa җир участогы булган эт хуҗалары үзләренең хайваннарын бик яхшы әйләндерелгән территориядә генә ирекка җибәрә алалар яки бәйдә генә йөртергә хокуклылар. Участокка кергәндә эт барлыгы турында кисәтүче язу булырга тиеш.

Урамда яки башка җәмәгать урыннарында хуҗасыз йөргән этләр, иясез этләр һәм мәчеләр ауланырга тиеш. Этләрне башка шәһәрләргә, районнарга, өлкәләргә сату яки алып бару яки читтән сатып алу хайванга ясалган прививкалар турында билгесе булган ветеринар таныклыгы булганда гына рөхсәт ителә.

Эт һәм мәче хуҗаларының бурычлары:

әйләнә - тирәдәгеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итүче тиешле чаралар күрергә;

торак йортларда тынлыкны тәэмин итәргә;

эт һәм мәчеләрне балалар мәйданчыкларына, кибетләргә, ашханәләргә һ.б. шундый гомуми куллану урыннарына җибәрмәскә;

этләрне үзвакытында теркәргә һәм яңадан теркәргә;

хайваннар белән кешелекле мөнәсәбәттә булырга (чыгарып ташламаска) тиешләр.

Ветеринария белгечләре таләбе буенча эт һәм мәчеләрне карауга, диагностик тикшерүләргә, прививкаларга һәм профилактик дәвалау чараларына алып килергә;

эт яки башка хайван тешләве турында сәламәтлек саклау органнарына һәм ветеринар учреждениеләргә кичекмәстән хәбәр итәргә һәм 10 көн дәвамында әлеге хайванны карау һәм белгечләр күзәтүе астында карантинда тоту өчен якындагы ветеринар учреждениегә алып килергә;

эт һәм мәчеләрнең кинәттән үлү яки бу хайваннарның котыру очраклары булганда кичекмәстән ветеринар учреждениегә хәбәр итәргә һәм ветеринария белгечләре килгәнгә кадәр авыру хайванны аерым тотарга;

эт һәм мәчеләрнең үле гәүдәләрен чыгарып ташлауга юл куймаска тиешләр.

Бу кагыйдәләрне үтәмәгән өчен эт һәм мәче хуҗалары закон белән билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартылалар.

Этләр һәм мәчеләр тарафыннан китерелгән зыян гамәлдәге законнар нигезендә аларның хуҗалары тарафыннан түләнә.

Эт сатып алырга теләгән һәркем: эт- кешенең дусты,дип кенә түгел, кеше дә этнең дусты, дип уйланырга тиешлеген онытмасын. Ә күпме этләр кеше кайгыртуыннан читтә кала. Хуҗасыз, ач хайваннар арасында котыру авыруы килеп чыгу мөмкинлеге зур һәм моннан котылу юлы бер генә: инфекция чыганагын юк итәргә кирәк. Бу рәхимсезлекнең нигезе- кешеләрнең шәфкатьсезлегендә. Язмыш кочагына ташланган авыру һәм мескен хайван кешелекнең хыянәтенә тере гаепләү ул, дип юкка гына әйтмәгәннәр.

**Т.СОРЕНКОВА,**
**Дәүләт санэпидкүзәтчелеге үзәге врач - эпидемиологы.**

## ЭТЛӘР - ИР - АТКА, МӘЧЕЛӘР - ХАТЫН - КЫЗГА

***Норвегияле доктор Эйлиф Дал илдә кешеләрнең төрле хайваннар тарафыннан тешләнүенә бәйле тикшеренүләрдән соң, кызыклы нәтиҗәләр ясады. Этләр күбрәк ирләрне, мәчеләр - хатын - кызларны, атлар - кыз балаларны тешли икән. Эйлиф Дал 1993 - 1995 елларда Осло шәһәренең иң зур клиникасында 1051 тешләнү очрагын җентекләп өйрәнде. Ул чыгарган нәтиҗә саннарда болай чагыла: эт тешләгән ирләр - 60, мәче тешләгән хатын - кызлар 70, ат тешләгән кечкенә кызлар исә 68 процент тәшкил итә.***

***Гомумән, кешеләрне күбесенчә этләр тешли. Аннан соң мәчеләр, атлар, еланнар, кимерүче җәнлекләр һәм кошлар килә.***

*("Заман - Татарстан" газетасыннан).*


## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА. БЕЛДЕРҮЛӘР.

### САТАБЫЗ

**К.Маркс ур., 6 адресы буенча 3 бүлмәле фатир.** Тел.: 2-16-59.

***

**Ленинград урамындагы төзелеп бетмәгән йортта 3 бүлмәле фатир (2нче кат),"Локомотив" ширкәтендә дача, яңа "Урал" мотоблогы, Тельман урамында гараж.**

Тел.: 2-19-77, иртәнге 8дән кичке 5кә кадәр, шимбә белән якшәмбедән кала.

***

**Ашыгыч төстә Октябрьнең 40 еллыгы урамында йорт яны корылмалары белән бнчы йорт.** Тел.: 3-04-85.

***

**Азык - төлек комбинаты ягында капиталь гараж.** Адрес: Завод ур., 26 - 4, теләсә кайчан.

***

**ВАЗ - 2106.**
Әхмәт авылында Т.В.Мостафинга мөрәҗәгать итәргә.

***

**1,30 х 1,60 лы пыяла.** Тел.: 2-24-03.

***

**10 х 10лы алтыпочмаклы бура.** Иске Максимкино авылында Владимир Ильич Смешниковка мөрәҗәгать итәргә, тел.: 71-2-30.

***

**Әфган поселогында участок, йорт һәм гараж нигезе, коесы бар.**
Тел.:5-26-39.

***

**Гараж капкасы.**
Тел.: 5-12-47.

***

**Ашыгыч төстә компьютер.** Тел.: 5-18-07.

***

**Ашыгыч төстә шәһәр үзәгендә өч бүлмәле (ремонт кирәкми), Козлов урамында ике бүлмәле фатирлар, Чишмә поселогында йорт.**
Тел.: 5-17-04 (кичке 8дән соң).

***

**Шикәр заводы ягында ике бүлмәле фатир.**
Тел.: 2-26-99, арадашчы аркылы.

***Идел Буе региональ наркология үзәге***

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.*

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

***Бездә генә!***

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга 28 нче август көнне, көндезге сәгать 11дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.

### САТАБЫЗ ЯКИ АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Нурлат шәһәрендәге 2 бүлмәле фатирны сатабыз яки Әлмәт шәһәрендәгегә алмаштырабыз.**
Тел.: 3-76-64 (Әлмәт шәһәре).

### САТЫП АЛАМ

**Пианино.** Тел.: 5-14-00.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Өч яшьлек баланы карарга кеше кирәк.**
Тел.: 5-37-50.

## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА. БЕЛДЕРҮЛӘР.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Николай Иванович Иванов исеменә Әфган поселогы ягында 21 август көнне югалган документларны табучының бүләк бәрабәренә иясенә кайтарып бирүен сорыйм.**

Адрес: Октябрьнең 60 еллыгы ур., 9 - 13.

***

**Юныс Хәлил улы Хәнәфиев исеменә шофер таныклыгы, ВАЗ - 2101гә тех.паспорт табучының бүләк бәрабәренә иясенә кайтарып бирүен сорыйм.**

Адрес: Якты Күл авылы.

***Хөрмәтле сатып алучылар!***

***Балаларына мәктәпкә киемнәр, сумка, рюкзак алырга өлгермәгән кешеләрне безнең бүлеккә чакырабыз.***

***Адресыбыз: "Балалар дөньясы" кибетенең 2нче катындагы коммерция бүлеге.***

***Лицензия № 288925***

### ФАТИР КИРӘК

**Барлык уңайлыклары белән, җиһазлы 1 яки 2 бүлмәле фатир.** Тел.: 2-23-27, кичке 8дән соң.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр:Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.
Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2353 данә. 3357